**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

**КАРАР**
IV чакырылыш чираттан тыш утырышы

2022 елның 28 гыйнваре № 3 Урыссу ш.т.п.

Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2021 елның 29 октябрендәге 83 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турында Нигезләмәгә өстәмәләр кертү хакында

Россия Федерациясе Конституциясе, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Советының 2020 елның 28 апрелендәге 18 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы районы Советы карар кабул итә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2021 елның 29 октябрендәге 83 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турында Нигезләмәгә түбәндәге өстәмәләр кертергә:

1.1. Түбәндәге эчтәлекле 8 статья өстәргә:

**«8. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге**

Контроль астындагы затның Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында муниципаль контроль өлкәсендә билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне бозуның ярамавы турында календарь ел дәвамында өч һәм аннан күбрәк кисәтүләре булуы.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан

Республикасы Дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының «Рәсми Татарстан» Бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы район Советының законлылык, регламент һәм җирлекләр Советлары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башлыгы -
Татарстан Республикасының
Ютазы район Советы Рәисе А.Ә. Шәфигуллин.